**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

«24» декабрь 2025 ел  № 22  Урыссу ш.т.б.

2026 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга өстәмә акчалар бүлеп бирү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ санлы 24.5 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 20.03.2025 № 33-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләрен карап һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. 2026 елга суд карарларын, контроль-күзәтчелек органнары күрсәтмәләрен һәм таләпләрен үтәү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга өстәмә акчалар бүлеп бирүдән әлеге карарга кушымта нигезендә баш тартырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе  А.Ә. Шәфигуллин